Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
« Гимназия № 183» Советского района г.Казани

| | |
|---|---|
| **СОГЛАСОВАНО** | **УТВЕРЖДАЮ** |
| Заместитель директора<br>по ВР Николаева А.Р.<br>_______________<br>28 августа 2025 г. | Директор МБОУ «Гимназия 183»<br>_________ С.А.Галиева<br>Приказ № 203 от 29 августа 2025 г |

Дополнительная общеобразовательная (общеразвивающая)
программа
«Театр сөючеләр»
Направление: художественное
Возраст обучающихся: 9-15 лет
Срок реализации: 2025-2026 уч.год

Составитель:
Хашитова Л.С.,
руководитель кружка

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
Протокол №1
от 29 августа 2025 г.

## Аңлатма язуы

Казан шәһәре 183 нче гомуми урта белем бирү гимназиясенең **"Театр сөючеләр"** драма түгәрәгенең эш планы. Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырыла. "Театр сөючеләр" драма түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучылар өчен оештырыла. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп, араларында матур җырлаучылар, биюгә оста кызлар-малайлар бар. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр дигән фикергә килдем. Әлеге программага нигезләп үткәрелгән түгәрәк эше укучыларга ярдәм итәр, матур сөйли,аралаша, үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтер дип ышанам. Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла Түгәрәктә йөрүче укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк тыныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотылды.

Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр, мәсәл укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала.

"Күңелле сәхнә" драма түгәрәге берләшмәсе 9-15 яшьлек укучылар өчен оештырыла. Дәресләр атнага 4,5 сәгать хисабыннан. (Барлыгы 144 сәгать)

**Максат:**

Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру, Һөнәри омтылышларын, сәләтләрен ачарга, матур сөйли, үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтү. Театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Үстерелешле максат:**

1. Сәнгатьле уку һәм сөйләм кунекмәләрен үстерү.
2. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.
3. Сәхнә осталыгын үстерү өстендә эшләү

**Бурычлар:**

- Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
- Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
- Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.

- Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

- Аеруча балалар өчен язылган һәм классик әсәрләр сәхнәләштерү, иҗат итү.

- Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар,балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр алдында чыгышлар ясау.

- Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

- Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгы арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү; - хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;

- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү;

- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудыру;

- музыка һәм хореография сәнгатенигезләребеләнтанышу;

- укучыларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышкаашыру;

- балаларныңсәламәтлеген яхшырту;

- сәнгатькә кызыксынуһәммәхәббәттәрбияләү.

Түгәрәк дәресләре төрле формада уткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

**Түгәрәк эше буенча көтелгән нәтиҗәләр:**

-укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;

-үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;

-түгәрәктәге укучылар, укытучы белән аралашу вакытында, эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;

-укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;

-сөйләм телен камилләштерә;

-әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;

-шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;

-татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби -музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача

**“Театр сөючеләр” түгәрәге программасының актуальлеге:** Кереп баручы стандартларының яңалыгы – белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үзфикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлилдә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

1. Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.

2. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
3. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү
4. Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.
5. Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
6. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

## Программаның эчтәлеге

**I. Кереш.**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II.Татар театры тарихы**.

Аның беренче адымнары, үткән юлы. Татар театрының бүгенгесе

**III. Без – яшь артистлар.**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау.

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.

**IV. Сәхнә уеннары.**

Драма жанры төрләре белән танышу.

Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълумат бирү. “Бүре башы”әсәрен өйрәнү, сәхнәдә кую.

Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау. “Туган тел көне”, Бөек татар язучылары һәм шагыйрьләренең туган көннәрен билгеләп үтү, кичәләр оештыру.

**V. Шигъри сәхнә**

Нәфис сүз сәнгате
Әсәрне иҗат итәргә әзерләү, актерлык серләрен өйрәнү.Әсәрне сәхнәгә кую (актерлык талантын тикшерү, ныгыту).Экскурсия, очрашулар. Бөек татар язучылары һәм шагыйрьләренең туган көннәрен билгеләп үтү, кичәләр оештыру. Милли бәйрәмнәр” Нәүрүз”, ”Карга боткасы”.һ.б уздыру.
**VI. Йомгаклау.**

**Тематик планлаштыру**

| **№** | **Эш төре** | **Гомуми сәг. саны** | **Теоретик сәг. саны** | **Практик сәг. саны** | **Дата** | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **план** | **фактик** |
| **I.** | **Кереш** | **2** | | | | |
| 1. | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | 2 | 2 | | 1атна | |
| **II.** | **Татар театры тарихы** | | | | | |
| 1. | Татар дөньясында беренче театр оешу. | 2.5 | 2.5 | | 1атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә. | 2 | 2 | | 2атна | |
| 3. | Габдулла Кариев һәм “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге. | 2.5 | 2.5 | | 2атна | |
| 4. | Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин – татар театрын оештыручылар. | 2 | 2 | | 3атна | |
| 5. | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрлары белән танышу | 2.5 | 2.5 | | 3атна | |
| 6. | Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры,Әкият курчак театры белән танышу | 2 | 2 | | 4атна | |
| **III.** | **Без – яшь артистлар** | | | | | |
| 1. | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 2,5 | 1 | 1,5 | 4атна | |
| 2. | Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | 2 | 2 | | 5атна | |
| 3. | Киенү-бизәнү осталыгы. | 2,5 | 2,5 | | 5атна | |
| 4 | Декорациянең роле. Видеоязмалар карау. | 2 | 2 | | 6атна | |
| 5 | Габдулла Тукайның мәсәлләре,әкиятләре,шигырь ләре белән танышу | 2,5 | | 2,5 | 6атна | |
| 6. | Габдулла Тукайның мәсәлләренә,әкиятләренә,шиг ырьләренә нигезләнеп язылган инценировкалар иҗат итү. | 2 | | 2 | 7атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Габдулла Тукайның мәсәлләренә,экиятләренә,шигырьләренә нигезләнеп язылган инценировкалар иҗат итү. | 2,5 | | 2,5 | 7атна | |
| 8. | Сәхнә сөйләме. | 2 | | 2 | 8атна | |
| 9. | Укучыларның иҗади эшләрен сәхнәләштерү | 2,5 | 1 | 1,5 | 8атна | |
| 10. | Укучыларның иҗади эшләрен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 9атна | |
| 11. | Сәхнә сөйләменә өйрәтү | 2,5 | 1 | 1,5 | 9атна | |
| 12. | Гәрәй Рәхимнең “Аля-шәр туны яки яңа мода ничек туа”әсәрен уку,өйрәнү | 2 | | 2 | 10 атна | |
| 13. | Орфоэпия | 2,5 | 1 | 1,5 | 10 атна | |
| 14. | Гәрәй Рәхимнең “Аля-шәр туны яки яңа мода ничек туа”әсәрен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 11 атна | |
| 15. | Гәрәй Рәхимнең “Аля-шәр туны яки яңа мода ничек туа”әсәрен сәхнәләштерү | 2,5 | 1 | 1,5 | 11 атна | |
| 16. | Гәрәй Рәхимнең “Аля-шәр туны яки яңа мода ничек туа”әсәре өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2 | | 2 | 12 атна | |
| 17. | Грим турында төшенчә | 2,5 | | 2,5 | 12 атна | |
| 18. | Ут, тавыш, музыкаль бизәлешләрен кертеп уйнап карау (монтировка) | 2 | | 2 | 13 атна | |
| 19. | Прогон репетицияләр | 2,5 | | 2,5 | 13 атна | |
| 20. | Гәрәй Рәхимнең “Аля-шәр туны яки яңа мода ничек | 2 | | 2 | 14 атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | туа”,Фаил Шәфигуллинның “Театр училищесында”,” Айлы төндә”әсәрләрен мәктәп сәхнәсендә уйнау | | | | | |
| 21. | “Шалкан” әкиятен уку | 2,5 | | 2,5 | 14 атна | |
| 22. | “Шалкан”әкиятенә ияреп яңача сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 15 атна | |
| 23. | “Шалкан”әкиятенә ияреп яңача сәхнәләштерү | 2,5 | | 2,5 | 15 атна | |
| 24. | “Шалкан”әкиятен сәхнәгә кую | 2 | | 2 | 16 атна | |
| **IV.** | **Сәхнә уеннары** | | | | | |
| 1. | Такмак, такмаза, тел шомарткычлар. | 2,5 | 1 | 1,5 | 16 атна | |
| 2. | Драма жанры төрләре:<br><br>1. Трагедия жанры<br>2. Комедия жанры<br>3. Драма жанры<br>4. Башка жанр төрләре:<br>- водевил<br>- мелодрама һ.б. | 2 | 2 | | 17 атна | |
| 3. | Конфликт турында төшенчә | 2,5 | 2,5 | | 17 | |
| 4. | Актерлык серләренә өйрәнү, өйрәтү дәресләре | 2 | | 2 | 18 атна | |
| 5. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәренең эчтәлеге белән танышу. | 2,5 | 2,5 | | 18 атна | |
| 6. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен рольләргә бүлеп уку. | 2 | | 2 | 19 атна | |
| 7. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен сәхнәләштерү | 2,5 | | 2,5 | 19 атна | |
| 8. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 20 атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Хәрәкәтләрне, бию өлешләрен өйрәнү. | 2,5 | | 2,5 | 20 атна | |
| 10. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 21 атна | |
| 11. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен сәхнәләштерү | 2,5 | | 2,5 | 21 атна | |
| 12. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәрен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | 22 атна | |
| 13. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәре өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2,5 | | 2,5 | 22 атна | |
| 14. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәре өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2 | | 2 | 23 атна | |
| 15. | Г.Рәхимнең «Бүре башы» әсәре өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2,5 | | 2,5 | 23 атна | |
| 16. | Сценарийны кабатлау. Музыкаль бизәлеш. Киемнәр әзерләү | 2 | | 2 | 24 атна | |
| 17. | Ут, тавыш, музыкаль бизәлешләрен кертеп уйнап карау (монтировка) | 2,5 | | 2,5 | 24 атна | |
| 18. | Прогон репетицияләр | 2 | | 2 | 25 атна | |
| 19. | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. | 2,5 | | 2,5 | 25 атна | |
| 20. | Спектакльны иҗат берлегенә тапшыру. | 2 | | 2 | 26 атна | |
| 21 | Премьера | 2,5 | | 2,5 | 26 атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Спектакльдан соң фикерләр белән уртаклашу | 2 | 2 | | 27 атна | |
| **V.** | **Шигъри сәхнә** | | | | | |
| 1. | Нәфис сүз сәнгате | 2,5 | 1,5 | 1 | 27 атна | |
| 2 | Шигырьләрне давам итү | 2 | | 2 | 28 атна | |
| 3 | Сәнгатьле сөйләмне тулысынча үзләштерү образлы сөйләргә ирешү | 2,5 | | 2,5 | 28 атна | |
| 4. | “Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына әзерләнү | 2 | | 2 | 29 атна | |
| 5. | “Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына әзерләнү | 2,5 | | 2,5 | 29 атна | |
| 6 | “Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына әзерләнү | 2 | | 2 | 30 атна | |
| **7** | “Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына костюмнар әзерләү | 2,5 | | 2,5 | 30 атна | |
| 8 | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. | 2 | | 2 | 31 атна | |
| 9 | Шигырь бәйрәмендә катнашу | 2,5 | | 2,5 | 31 атна | |
| 10. | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү | 2 | | 2 | 32 атна | |
| 11. | Такмак әйтешле уеннар. | 2,5 | | 2,5 | 32 атна | |
| 12. | Г.Камал исемендәге татар дәүләт Академия театрына экскурсия оештыру | 2 | | 2 | 33 атна | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Балалар өчен җырлар өйрәнү. | 2,5 | | 2,5 | 33 атна | |
| 14. | “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру | 2 | 2 | | 34 атна | |
| **VI.** | **Йомгаклау** | | | | | |
| 1. | Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | 2,5 | 2,5 | | 34 атна | |

**Кулланма әдәбият**


1. “Әдәбият белеменә кереш”.
2. Татар халык әкиятләре.
3. “Тәрбия” газетасы.
4. “Ачык дәрес” газетасы.
5. “Җырлыйк әле” җыр китабы.
6. Х. Халиков “Зиһен ачкычлары”
7. “Мәктәп сәхнәсе” китабы.
8. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар.
9. “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
10. Габдулла Тукай әсәрләре.
11. Туфан Миңнуллин. Сайланма әсәрләр. Хәтер- 2008 нче ел.
12. Татар драматургиясе (1960-1980 нче еллар). Сайланма әсәрләр Тарих-200.
13. Драматургиядә утлы еллар авазы (1941-1945) Бөек Җиңүнең 80 еллыгына карата чыгарылган әдәбият.
14. Галиәсгар Камал.Әсәрләр,2 том
15. “Пионер сәхнәсе”китабы,1978 ел.

В данном документе пронумеровано, прошнуровано и скреплено печатью 11 (одиннадцать) страниц

Директор МБОУ «Гимназия №183» Советского района г.Казани

______________ С.А. Галинова.

МБОУ «Гимназия №183»